**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2025 **Чирмешән авылы** **№ 399**

**«2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 910 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов

ТР Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 17 декабрендәге №399
карары белән расланды

**«Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү»**
**муниципаль программасы**

## «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль[1] программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик өстенлекләр

## I. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәт өлкәсендәге агымдагы торышны бәяләү[2]

Муниципаль идарәнең нәтиҗәле системасы җирле үзидарә органнарының динамикалы үсешенең иң мөһим шарты булып тора.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының җирле үзидарә органнарында халыкның тормыш сыйфатын күтәрү максатларында җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән, заманча таләпләргә туры килә торган бердәм кадрлар сәясәте төзелде.

Муниципаль хезмәтнең нәтиҗәле кадрлар составын формалаштыру Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында гамәлгә ашырыла торган кадрлар сәясәтенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора.

Хәзерге вакытта федераль кануннар нигезендә дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар потенциалын сайлап алу һәм комплекслы бәяләү, идарәче кадрларны бәяләү, кадрлар резервларын булдыру системалары эшли, алар гади һәм идарә итү вазыйфаларын югары квалификацияле кадрлар белән оператив рәвештә биләргә мөмкинлек бирә.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрне әзерләүнең комплекслы системасы булдырылды һәм эшли, ул хезмәткәрләрнең барлык категорияләрен колачлауны һәм аларның һөнәри үсешенең өзлексезлеген тәэмин итә. Белем бирү процессына заманча технологияләр кертү буенча даими эш алып барыла, мобиль мәгълүмати-белем бирү платформасы эшләнде һәм кулланыла.

Җирле үзидарә органнарының кадрлар составын укытуның формалаштырылган системасы кысаларында муниципаль районнарның һәм шәһәр

[1] Муниципаль программаның стратегик өстенлекләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.11.2013 № 910 карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында муниципаль берәмлекнең өстенлекләре һәм максатлары нигезендә үзгәртелергә яисә киңәйтелергә мөмкин.
[2] Стратегик өстенлекләрнең I бүлегендә шулай ук бүгенге көндә муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәтнең торышы турында мәгълүмат күрсәтелә.

округларының җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм белгечләре, авыл җирлекләре башлыклары, авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары һәм башка категорияләр өчен махсус укыту программалары циклы гамәлгә ашырыла. Муниципаль кадрларның квалификациясен һәм һөнәри әзерлек дәрәҗәсен даими рәвештә күтәрүне дәвам итү мөһим.

Муниципаль хезмәтнең ачыклыгын һәм җәмәгать контроленнән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Вакантлы вазыйфалар турында, муниципаль хезмәткә керү тәртибе турында, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше турында актуаль мәгълүмат урнаштырыла.

Муниципаль идарә системасында дәүләт идарәсе белән беррәттән мәгълүмат технологияләрен кертү һәм куллану исәбенә кадрлар эшенең нәтиҗәлелеген камилләштерүгә һәм күтәрүгә аерым игътибар бирелә. 2013 елда башланган кадрлар эшен цифрлаштыру проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә хәзерге вакытка персонал белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмати пространство булдырылды, аның һәр элементы кадрлар эшенең гомуми процессына үрелеп бара. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәй мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – бердәй мәгълүмат кадрлар системасы) мәгълүмат киңлегенең үзәк звеносы булып тора, ул кадрлар эшенең бердәй стандартларын кертүгә, бердәй исәпкә алу сәясәтен булдыруга һәм кадрлар процессларын оптимальләштерү исәбенә муниципаль хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга ярдәм итте.

## II. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль программаны гамәлгә ашыру өлкәсендә муниципаль сәясәтнең өстенлекләре һәм максатлары тасвирламасы

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы районда муниципаль хезмәтне үстерүгә юнәлдерелгән.

Муниципаль программаның өстенлекләре «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указына, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә (алга таба – Стратегия-2030), Татарстан Республикасы Президентының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүнең төп юнәлешләре турында»2021 елның 21 маендагы ПУ-398 номерлы Указына туры килә.

## III. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль идарә бурычлары, аларны муниципаль хезмәтне үстерү өлкәсендә нәтиҗәле хәл итү ысуллары

Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегик максатларына һәм бурычларына ирешү өчен Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль программасының максатлары һәм бурычлары билгеләнде, күрсәткечләр структурасы һәм системасы эшләнде.

Муниципаль программаның максатлары һәм бурычлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.11.2013 № 910 карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатларына туры килә (алга таба – дәүләт программасы).

## «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы паспорты

### 1. Төп нигезләмәләр

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасы |
| Муниципаль программаның җаваплы башкаручысы | Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Муниципаль программаның максатлары | 1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру.<br>2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәттә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү |
| Муниципаль программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары аппараты эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша.<br>2. Муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алу, аларның эшчәнлегенә комплекслы бәя бирү һәм хезмәттә алга этәрүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү, шулай ук талантлы, инициативалы хезмәткәрләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү.<br>3. Муниципаль идарә өлкәсендә кеше капиталын үстерү һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен тулы цикллы белем бирү мохитен булдыру.<br>4. Муниципаль хезмәттә мотивацияләүнең, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү.<br>5. Җирле үзидарә органнарының хезмәт культурасын камилләштерү, муниципаль хезмәт |

| | |
|---|---|
| | системасында лидерлык һәм патриотизмны үстерү.<br>6. Муниципаль хезмәтнең абруен күтәрү, һөнәри мотивацияле яшьләрне җәлеп итү һәм югары квалификацияле белгечләрне саклап калу өчен уңайлы шартлар тудыру.<br>7. Җәмәгать контроле һәм граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек системасын үстерү, муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру.<br>8. Муниципаль хезмәтне норматив һәм методик яктан тәэмин итү.<br>9. Муниципаль хезмәтнең кадрлар составы белән идарә итүне оптимальләштерү өчен кадрлар эшендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану. |
| Муниципаль программаны гамәлгә ашыру чоры | **2026 - 2028 еллар** |
| Муниципаль программаны финанс белән тәэмин итү күләмнәре | Финанс белән тәэмин итү күләме гамәлгә ашыруның бөтен чорында 2199,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2026 елда – 664,4 мең сум;<br>2027 елда – 730,8 мең сум;<br>2028 елда – 803,88 мең сум. |

## 2. Муниципаль программа күрсәткечләре

| № п/п | Муниципаль программаның максатлары/бурычлары/күрсәткечләре[3] | Җаваплы башкаручы[4] | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел[5] | | | Раслаучы документ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| **Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәтендә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү** | | | | | | | |
| 1. | Җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша | | | | | | |
| 1.1. | Дәүләт программасында билгеләнгән чорга муниципаль хезмәтне үстерүнең расланган (актуальләштерелгән) муниципаль программасы булу | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 1.2. | Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткә керүгә һәм аны узуга бәйле хокукый актларын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарындагы үзгәрешләрне исәпкә алып актуальләштерү | Район Советы Аппараты җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |

[3] Муниципаль программа паспортының 2 бүлегенә муниципаль программа паспортының 1 бүлегендә күрсәтелгән бурычлар нигезендә өстәмә күрсәткечләр өстәлергә мөмкин (мәсәлән, муниципаль хезмәткәрләрнең мотивациясен арттыруга һәм стимуллаштыруга, муниципаль кадрларның алмашынучанлыгын киметүгә, муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә социаль гарантияләр билгеләүгә юнәлдерелгән чараларга кагылышлы күрсәткечләр, муниципаль хезмәткәрләрнең мактау тактасы һ.б.).

[4] Муниципаль программа паспортының 2 бүлегенең 3 баганасында муниципаль программа күрсәткечләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы структур бүлекчәләр йә вазыйфаи затлар күрсәтелә.

[5] Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.11.2013 № 910 карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында муниципаль программа күрсәткечләренең 2 бүлегендәге 5 баганадагы мәгънәләре муниципаль берәмлекнең өстенлекләреннән һәм максатларыннан чыгып үзгәртелергә мөмкин.

| № п/п | Муниципаль программаның максатлары/бурычлары/күрсәткечләре[3] | Җаваплы башкаручы[4] | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел[5] | | | Раслаучы документ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 | |
| | | буенча баш белгече | | | | | |
| 2. | Муниципаль идарә өлкәсендә кеше капиталын үстерү һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен тулы циклльы белем бирү мохитен булдыру | | | | | | |
| 2.1. | Өстәмә һөнәри белем бирүне дә кертеп, һөнәри үсеш чараларында катнашучы муниципаль хезмәткәрләр өлеше | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 33 | 33 | 33 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 2.2. | Һөнәри үсеш барышында теркәлгән һәм мәгълүмати-белем бирү платформасыннан (мобиль кушымтадан) файдаланучы муниципаль хезмәткәрләр өлеше | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 90 | 90 | 90 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 2.3. | Муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | берәмлек | 2 | 2 | 2 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 3. | Җәмәгать контроле һәм граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек системасын үстерү, муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы | | | | | | |

| № п/п | Муниципаль программаның максатлары/бурычлары/күрсәткечләре[3] | Җаваплы башкаручы[4] | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел[5] | | | Раслаучы документ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 | |
| | көрәш чараларын гамәлгә ашыру | | | | | | |
| 3.1. | Муниципаль хезмәткәрләр билгәндә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (алга таба - керемнәре турында белешмәләр) тапшырырга тиешле вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең dohod.tatar.ru аша «БК белешмәләре» тәэмин итүнең махсуслаштырылган программасы форматындагы файлларны йөкләү функционалыннан файдаланып керемнәр турында белешмәләрне тапшырган өлеше | Башлыкның коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 100 | 100 | 100 | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасы мәгълүматлары |
| 3.2. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның аны узуга бәйле таләпләрне һәм чикләүләрне үтәвенә үткәрелгән тикшерүләр өлеше | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Башлыкның коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |

| № п/п | Муниципаль программаның максатлары/бурычлары/күрсәткечләре[3] | Җаваплы башкаручы[4] | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел[5] | | | Раслаучы документ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 | |
| 3.3. | Социаль челтәрләрдә һәм башка заманча мәгълүмат-коммуникация платформаларында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны, массакүләм мәгълүмат чараларындагы мәкаләләрне урнаштыру | Башлыкның коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | берәмлек | 20 | 20 | 20 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 3.4. | Муниципаль хезмәт ветераннары һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашулар оештыру | Район Советы Аппараты җитәкчесе, район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече, җирлек башлыклары | берәмлек | 2 | 2 | 2 | муниципаль хезмәт ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар белән үзара хезмәттәшлек өчен җаваплы вазыйфаи затларның күрсәткечләре |
| 4. | Муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алу, аларның эшчәнлеген комплекслы бәяләү һәм хезмәттә алга җибәрүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү, шулай ук талантлы, инициатив хезмәткәрләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү | | | | | | |
| 4.1. | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы муниципаль | Мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмати иминлек бүлеге | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |

| № п/п | Муниципаль программаның максатлары/бурычлары/күрсәткечләре[3] | Җаваплы башкаручы[4] | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел[5] | | | Раслаучы документ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 | |
| | берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру | башлыгы, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | | | | | |
| 4.2. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүне үткәрү, шул исәптән «Кадрларны бәяләү системасы» функционалын кулланып тест үткәрү | Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 4.3. | Идарәче кадрлар резервына кертелгән затлар саны | Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | кеше | 3 | 0 | 3 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 4.4. | Муниципаль хезмәткәрләрнең кадрлар резервын формалаштыру һәм актуальләштерү | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 4.5. | Җирле үзидарә органнарында һәм | Район Советы | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте |

| № п/п | Муниципаль программаның максатлары/бурычлары/күрсәткечләре[3] | Җаваплы башкаручы[4] | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел[5] | | | Раслаучы документ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 | |
| | муниципаль учреждениеләрдә остазлык оештыру | Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре | | | | | күрсәткечләре |
| 4.6. | Муниципаль хезмәт резервчыларын укытуны оештыру, аларның карьера хәрәкәтләренә булышлык күрсәтү | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | берәмлек | 2 | 2 | 2 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 4.7. | Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрен актуальләштерү | Район Советының Аппарат җитәкчесе, район Советының юридик бүлеге начальнигы, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |

| № п/п | Муниципаль программаның максатлары/бурычлары/күрсәткечләре[3] | Җаваплы башкаручы[4] | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел[5] | | | Раслаучы документ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 | |
| 5. | Муниципаль хезмәтнең абруен күтәрү, һөнәри мотивацияле яшьләрне җәлеп итү һәм югары квалификацияле белгечләрне саклап калу өчен уңайлы шартлар тудыру | | | | | | |
| 5.1. | Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар белән чаралар оештыру | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Район Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге», «Мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | берәмлек | 2 | 2 | 2 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 5.2. | Муниципаль хезмәтне популярлаштыруга юнәлдерелгән чараларны оештыру | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | берәмлек | 2 | 2 | 2 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |
| 5.3. | Муниципаль хезмәткәрләрнең «Муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» конкурсында катнашуы | Район Советы Аппараты җитәкчесе, Чирмешән муниципаль | кеше | 1 | 1 | 1 | җирле үзидарә органы кадрлар хезмәте күрсәткечләре |

| № п/п | Муниципаль программаның максатлары/бурычлары/күрсәткечләре[3] | Җаваплы башкаручы[4] | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел[5] | | | Раслаучы документ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 | 2027 | 2028 | |
| | | районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | | | | | |
| 6. | Муниципаль хезмәтнең кадрлар составы белән идарә итүне оптимальләштерү өчен кадрлар эшендә мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдалану | | | | | | |
| 6.1. | Кадрлар эшен оештыру һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы белешмәләрне бердәм мәгълүмати кадрлар системасында актуальләштерү | Чирмешән муниципаль районы Советының оештыру бүлегенең кадрлар буенча баш белгече | процентлар | 100 | 100 | 100 | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасы мәгълүматлары |

## 3. Муниципаль программа чаралары (нәтиҗәләре)[6]

| № п/п | Чараның (нәтиҗәнең) максаты/бурычы исеме | Үлчәү берәмлеге | Чор, ел | | | Чарага (нәтиҗәгә) характеристика | Чара (нәтиҗә) төре | Муниципаль программа күрсәткечләре белән элемтә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2026 | 2027 | 2028 | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| **Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәтендә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү.** | | | | | | | | |
| 1. | Җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша | | | | | | | |
| 1.1. | Дәүләт программасы белән билгеләнгән чорга муниципаль | процентлар | 100 | 100 | 100 | муниципаль хезмәтне үстерүнең муниципаль программасын кабул итү | хокукый акт кабул итү | дәүләт программасында билгеләнгән чорга муниципаль хезмәтне үстерүнең расланган |

[6] Муниципаль программа паспортының 2 бүлегенә өстәмә күрсәткечләр өстәлгән очракта, 3 бүлектә шулай ук алар белән бәйле чаралар (нәтиҗәләр) күрсәтелә. Моннан тыш, 3 бүлектә булган күрсәткечләр кысаларында чаралар (нәтиҗәләр) каралырга мөмкин.

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәтне үстерү муниципаль программасы расланды (актуальләштерелде) | | | | | (актуальләштерү) | | (актуальләштерелгән) муниципаль программасы булу |
| 1.2. | Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткә керүгә һәм аны узуга бәйле хокукый актлары актуальләштерелде | процентлар | 100 | 100 | 100 | җирле үзидарә органнарының хокукый актларын актуальләштерү | хокукый акт кабул итү | җирле үзидарә органнарының ел саен актуальләштерелгән хокукый актлары булуы |
| 2. | Муниципаль идарә өлкәсендә кеше капиталын үстерү һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен тулы цикллы белем бирү мохитен булдыру | | | | | | | |
| 2.1. | Муниципаль хезмәткәрләрне һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрне, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен һөнәри үстерү, шул исәптән өстәмә һөнәри белем бирү (квалификация күтәрү, һөнәри яңадан әзерләү) чараларында катнашу | процентлар | 33 | 33 | 33 | муниципаль хезмәткәрләрне һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрне, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен һөнәри үстерү, шул исәптән өстәмә һөнәри белем бирү (квалификация күтәрү, һөнәри яңадан әзерләү) чараларын оештыру | кадрларның квалификация сен күтәрү | өстәмә һөнәри белем бирүне дә кертеп, һөнәри үсеш чараларында катнашучы муниципаль хезмәткәрләр өлеше |
| 2.2. | Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль | процентлар | 100 | 100 | 100 | муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль | кадрларның квалификация сен күтәрү | өстәмә һөнәри белем бирүне дә кертеп, һөнәри үсеш чараларында катнашучы муниципаль |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль хезмәт вазыйфалары булып тормаган җирле үзидарә органнары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр мобилизацион әзерлек һәм дәүләт серен саклау мәсьәләләре буенча квалификация күтәрү чараларында катнаштылар | | | | | хезмәт вазыйфалары булып тормаган җирле үзидарә органнары вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр өчен мобилизацион әзерлек һәм дәүләт серен саклау мәсьәләләре буенча квалификация күтәрүне оештыру | | хезмәткәрләр өлеше |
| 2.3. | Муниципаль хезмәткәрләр һөнәри үсеш барышында теркәлгән һәм мәгълүмати-белем бирү платформасыннан (мобиль кушымтадан) файдалана | процентлар | 90 | 90 | 90 | муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше процессына мәгълүмат-белем бирү платформасын (мобиль кушымта) кертү | кадрларның квалификация сен күтәрү | һөнәри үсеш барышында теркәлгән һәм мәгълүмати-белем бирү платформасыннан (мобиль кушымтадан) файдаланучы муниципаль хезмәткәрләр өлеше |
| 2.4. | Муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар уздырылды | берәмлек | 2 | 2 | 2 | муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше буенча семинарлар, киңәшмәләр оештыру | кадрларның һөнәри дәрәҗәсен күтәрү | муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү |
| 3. | Җәмәгать контроле һәм граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек системасын үстерү, муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру | | | | | | | |
| 3.1. | Муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре турындагы белешмәләр dohod.tatar.ru аша «БК белешмәләре» н тәэмин итүнең махсуслаштырылган | процентлар | 100 | 100 | 100 | dohod.tatar.ru аша «БК белешмәләре» н тәэмин итүнең махсуслаштырылган программасы файлларын йөкләү функционалын гамәлгә ашыру өлешендә Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәт кадрлар | белешмәләр тапшыру | dohod.tatar.ru аша «БК белешмәләре» н тәэмин итүнең махсуслаштырылган программасы форматындагы файлларны йөкләү функционалыннан файдаланып керемнәр турында белешмәләр тапшырган, керемнәр турында |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | программасы форматындагы файлларны йөкләү функционалыннан файдаланып тапшырыла | | | | | составының бердәм мәгълүмат системасын модернизацияләү | | белешмәләр тапшырырга тиешле вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр өлеше |
| 3.2. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның аны узуга бәйле таләпләрне һәм чикләүләрне үтәве тикшерелде | процентлар | 100 | 100 | 100 | муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның аны узуга бәйле таләпләрне һәм чикләүләрне үтәвен тикшерү | тикшерүләр үткәрү | муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның аны узуга бәйле таләпләрне һәм чикләүләрне үтәвенә үткәрелгән тикшерүләр өлеше |
| 3.3. | Муниципаль хезмәтне популярлаштыруга һәм аның абруен күтәрүгә юнәлдерелгән материаллар социаль челтәрләрдә һәм башка заманча коммуникация платформаларында әзерләнде һәм урнаштырылды | берәмлек | 20 | 20 | 20 | социаль челтәрләрдән һәм башка мәгълүмат-коммуникация платформаларыннан файдалану аша муниципаль хезмәтне популярлаштыру һәм аның абруен күтәрү | «Интернет» челтәрендә мәгълүмат урнаштыру | социаль челтәрләрдә һәм башка заманча мәгълүмат-коммуникация платформаларында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматны, массакүләм мәгълүмат чараларындагы мәкаләләрне урнаштыру |
| 3.4. | Җирле үзидарә органнары коллективының муниципаль хезмәт ветераннары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашулары оештырылды | берәмлек | 2 | 2 | 2 | муниципаль хезмәт ветераннары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылар белән үзара хезмәттәшлек | очрашулар үткәрү | муниципаль хезмәт ветераннары һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашулар оештыру |
| 4. | Муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алу, аларның эшчәнлеген комплекслы бәяләү һәм хезмәттә алга җибәрүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү, шулай ук талантлы, инициатив хезмәткәрләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү | | | | | | | |
| 4.1. | Муниципаль | процентлар | 100 | 100 | 100 | муниципаль хезмәтнең | кадрлар белән | муниципаль хезмәтнең вакантлы |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырылган | | | | | вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат урнаштыру | эшләү | вазыйфалары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру |
| 4.2. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсенә бәя бирелде, шул исәптән «Кадрларны бәяләү системасы» функционалыннан файдаланып тест үткәрелде | процентлар | 100 | 100 | 100 | муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү | кадрлар белән эшләү | муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүне үткәрү, шул исәптән «Кадрларны бәяләү системасы» функционалын кулланып тест үткәрү |
| 4.3. | Чирмешән муниципаль районының идарәче кадрлар резервы формалаштырылды | процентлар | 100 | 0 | 0 | Чирмешән муниципаль районының идарәче кадрлар резервын формалаштыру | резерв формалаштыру | идарәче кадрлар резервына кертелгән затлар саны |
| 4.4. | Идарә итү вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы затларны идарәче кадрлар резервына кертү | кеше | 3 | 0 | 3 | Чирмешән муниципаль районының идарәче кадрлар резервын актуальләштерү | резервны актуальләштерү | идарәче кадрлар резервына кертелгән затлар саны |
| 4.5. | Җирле үзидарә органнарының яңа кабул ителгән хезмәткәрләре өчен остазлар билгеләнде | процентлар | 100 | 100 | 100 | Чирмешән муниципаль районында остазлык | кадрлар белән эшләү | җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль учреждениеләрдә остазлык оештыру |
| 4.6. | Муниципаль хезмәт резервистлары өчен лекцияләр, мастер-класслар һәм | берәмлек | 2 | 2 | 2 | Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәт резервистлары белән үзара хезмәттәшлек | кадрларның һөнәри дәрәҗәсен күтәрү | муниципаль хезмәт резервчыларын укытуны оештыру, аларның карьера хәрәкәтләренә булышлык күрсәтү |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | консультацияләр үткәрелде, аларның карьераларында ярдәм күрсәтелде | | | | | | | |
| 4.7. | Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләре актуальләштерелде | процентлар | 0 | 100 | 0 | вазыйфаи инструкцияләрне актуальләштерү | белешмәләрне актуальләштерү | муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрен актуальләштерү |
| 5. | Муниципаль хезмәтнең абруен күтәрү, һөнәри мотивацияле яшьләрне җәлеп итү һәм югары квалификацияле белгечләрне саклап калу өчен уңайлы шартлар тудыру | | | | | | | |
| 5.1. | Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар белән чаралар уздырылды | берәмлек | 2 | 2 | 2 | муниципаль хезмәтне популярлаштыру, шул исәптән Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучыларны укытуны оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек | укыту чаралары | Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар белән чаралар оештыру |
| 5.2. | Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары җирле үзидарә органнарында стажировка үттеләр | кеше | 2 | 2 | 2 | Чирмешән муниципаль районында Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары белән үзара хезмәттәшлек | укыту чаралары | Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар белән чаралар оештыру |
| 5.3. | Һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары белән төзелә торган шартнамәләр нигезендә җирле үзидарә органнарында студентлар өчен практикалар | берәмлек | 2 | 2 | 2 | Чирмешән муниципаль районында студентлар белән үзара хезмәттәшлек | укыту чаралары | муниципаль хезмәтне популярлаштыруга юнәлдерелгән чараларны оештыру |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (стажировкалар) үткәрелде | | | | | | | |
| 5.4. | Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре «Муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» конкурсында катнаштылар | кеше | 1 | 1 | 1 | муниципаль берәмлекләр муниципаль хезмәткәрләренең «Муниципаль идарә өлкәсендәге иң яхшы хезмәткәр» конкурсында катнашуы | конкурста катнашу | муниципаль берәмлекләр муниципаль хезмәткәрләренең «Муниципаль идарә өлкәсендәге иң яхшы хезмәткәр» конкурсында катнашуы |
| 6. | Муниципаль хезмәтнең кадрлар составы белән идарә итүне оптимальләштерү өчен кадрлар эшендә мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдалану | | | | | | | |
| 6.1. | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы актуаль белешмәләрнең булуы | процентлар | 100 | 100 | 100 | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында җирле үзидарә органнарының кадрлар бүлекчәләре хезмәткәрләренең кадрлар эшен алып баруын тәэмин итү | белешмәләрне актуальләштерү | кадрлар эшен оештыру һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы белешмәләрне бердәм мәгълүмати кадрлар системасында актуальләштерү |
| 6.2. | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында кадрлар эшен алып баруны тәэмин итү | процентлар | 100 | 100 | 100 | кадрлар эшен Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында алып бару | кадрлар системасы белән эшләү | кадрлар эшен оештыру һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы белешмәләрне бердәм мәгълүмати кадрлар системасында актуальләштерү |
| 6.3. | Кадрлар документлары өлешендә бердәм мәгълүмати кадрлар системасыннан һәм «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбенә | процентлар | 100 | 100 | 100 | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасыннан һәм «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар карамагындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбенә алуы һәм хисаплылыгы» дәүләт мәгълүмат системасыннан функциональ файдаланучылар арасында кадрлар | кадрлар системасы белән эшләү | кадрлар эшен оештыру һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы белешмәләрне бердәм мәгълүмати кадрлар системасында актуальләштерү |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | алуы һәм хисаплылыгы» дәүләт мәгълүмат системасыннан функциональ файдаланучылар арасында мәгълүмати үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү | | | | | документлары өлешендә мәгълүмати хезмәттәшлек | | |
| 6.4. | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасыннан файдаланып, муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару | процентлар | 100 | 100 | 100 | бердәм мәгълүмати кадрлар системасыннан файдаланып, муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару | кадрлар системасы белән эшләү | кадрлар эшен оештыру һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы белешмәләрне бердәм мәгълүмати кадрлар системасында актуальләштерү |
| 6.5. | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында җирле үзидарә органнарының кадрлар составы турындагы белешмәләрне кертү һәм исәпкә алу | процентлар | 100 | 100 | 100 | кадрлар составы турындагы белешмәләрне Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында кертү һәм исәпкә алу | кадрлар системасы белән эшләү | кадрлар эшен оештыру һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы белешмәләрне бердәм мәгълүмати кадрлар системасында актуальләштерү |

## 4. Муниципаль программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү[7]

| № п/п | Чараның (нәтиҗәнең) исеме һәм финанслау чыганаклары [8] | Гамәлгә ашыру еллары буенча финанс белән тәэмин итү күләме[9], мең сумнар | | | Барлыгы, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | |

[7] Муниципаль программа паспортының 2 һәм 3 бүлекләренә өстәмә күрсәткечләр һәм чаралар өстәлгән очракта, 4 бүлектә шулай ук аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күрсәтелә.
[8] 4 бүлектә 3 бүлектә каралган барлык чаралар, аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү булуга карамастан, күрсәтелә.
[9] Чараны (нәтиҗәне) финанс белән тәэмин итү кирәк булмаганда, 4 бүлектәге 3-6 баганаларда нульле күрсәткеч күрсәтелә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| **Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәтендә кадрлар эшенә заманча технологияләр кертү.** | | | | | |
| 1. | Җирле үзидарә органнары аппаратлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша – барлыгы, шул исәптән: | 664,4 | 730,8 | 803,88 | 2199,1 |
| | муниципаль бюджет: | 664,4 | 730,8 | 803,88 | 2199,1 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.1. | Дәүләт программасы белән билгеләнгән чорга муниципаль хезмәтне үстерү муниципаль программасы расланды (актуальләштерелде) – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 664,4 | 730,8 | 803,88 | 2199,1 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 1.2. | Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2. | Муниципаль идарә өлкәсендә кеше капиталын үстерү һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен тулы цикллы белем бирү мохитен булдыру – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2.1. | Муниципаль хезмәткәрләрне һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны, муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрне, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен һөнәри үстерү, шул исәптән өстәмә һөнәри белем бирү (квалификация күтәрү, һөнәри яңадан әзерләү) чараларында катнашу – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2.2. | Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр мобилизацион әзерлек һәм дәүләт серен саклау мәсьәләләре буенча квалификация күтәрү чараларында катнаштылар – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2.3. | Муниципаль хезмәткәрләр теркәлгән һәм мәгълүмати-белем бирү платформасын (мобиль кушымта) һөнәри үсеш барышында куллана-барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2.4 | Муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрелде – барлыгы, шул исәптән: | 664,4 | 730,8 | 803,88 | 2199,1 |
| | муниципаль бюджет: | 664,4 | 730,8 | 803,88 | 2199,1 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3. | Җәмгать контроле һәм граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек системасын үстерү, муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3.1. | Муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре турындагы белешмәләр dohod.tatar.ru аша «БК белешмәләре» н тәэмин итүнең махсуслаштырылган программасы форматындагы файлларны йөкләү функциональныннан файдаланып тапшырыла - барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3.2. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның аны узуга бәйле таләпләрне һәм чикләүләрне үтәве тикшерелде – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3.3. | Муниципаль хезмәтнең абруен күтәрүгә һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән материаллар социаль челтәрләрдә һәм башка заманча коммуникация платформаларында әзерләнде һәм урнаштырылды – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 3.4. | Җирле үзидарә органнары коллективының муниципаль хезмәт ветераннары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашулары оештырылды – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4. | Муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алуның, аларның эшчәнлеген комплексы бәяләүнең һәм хезмәт буенча алга җибәрүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү, шулай ук талантлы, инициатив хезмәткәрләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү – барысы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4.1. | Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфалары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырылды – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4.2. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсенә бәя бирелде, шул исәптән «Кадрларны бәяләү системасы» функционалын кулланып тест үткәрү – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4.3. | Районның идарәче кадрлары резервы формалаштырылды – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4.4. | Идарә итү вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы затларны идарәче кадрлар резервына кертү – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4.5. | Җирле үзидарә органнарының яңа кабул ителгән хезмәткәрләре өчен остазлар билгеләнде – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4.6. | Муниципаль хезмәт резервистлары өчен лекцияләр, мастер-класслар һәм консультацияләр үткәрелде, аларның карьера хәрәкәтләрендә булышлык күрсәтелде – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 4.7. | Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләре актуальләштерелде – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 5. | Муниципаль хезмәтнең абруен күтәрү, һөнәри мотивацияле яшьләрне җәлеп итү һәм югары квалификацияле белгечләрне саклап калу өчен уңайлы шартлар тудыру – барысы, шул исәптән: | 664,4 | 730,8 | 803,88 | 2199,1 |
| | муниципаль бюджет: | 664,4 | 730,8 | 803,88 | 2199,1 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 5.1. | Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар белән чаралар уздырылды – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 5.2. | Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары җирле үзидарә органнарында стажировка үттеләр – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 5.3. | Һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары белән төзелә торган шартнамәләр нигезендә җирле үзидарә органнарында студентлар өчен практикалар (стажировкалар) үткәрелде – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 5.4. | Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре «Муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» конкурсында катнаштылар – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 6. | Муниципаль хезмәтнең кадрлар составы белән идарә итүне оптимальләштерү өчен кадрлар эшендә мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану-барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 6.1. | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы актуаль белешмәләрнең булуы - барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 6.2. | Кадрлар эшен бердәм мәгълүмати кадрлар системасында алып баруны тәэмин итү - барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 6.3. | Бердәм мәгълүмати кадрлар системасыннан һәм «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбенә алуы һәм хисаплылыгы» дәүләт мәгълүмат системасыннан функциональ файдаланучылар арасында кадрлар документлары өлешендә – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 6.4. | Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестрын бердәм мәгълүмати кадрлар системасыннан файдаланып алып бару – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 6.5. | Җирле үзидарә органнарының кадрлар составы турындагы мәгълүматларны бердәм мәгълүмати кадрлар системасында кертү һәм исәпкә алу – барлыгы, шул исәптән: | | | | |
| | муниципаль бюджет: | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | бюджеттан тыш чыганаклар: | 0 | 0 | 0 | 0 |